СОВЕТ НИЖНЕУСЛОНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ТҮБӘН ОСЛАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ — КАРАР

18.09.2017 — с. Нижний Услон — 34-131

Җирле референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, Түбән Ослан авыл җирлеге Уставының 11 статьясы нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Түбән Ослан авыл җирлеге Советы
Карар итте:

1. Түбән Ослан авыл җирлеге территориясендә референдум үткәрүнең уртак инициативасын тәкъдим итү:

«Сез 2018 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия авыл җирлегенең һәр кешесеннән 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен ризамы:

Түбән Ослан, Воробьевка авыллары җирле әһәмияттәге юлларны вак таш салу чараларын уздыру.

ӘЙЕ — ЮК

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар имзаланган көннән үз көченә керә.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Түбән Ослан авыл җирлеге башлыгы — А. З. Шәйдуллин